**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 25 декабрендәге 4651 номерлы карары**

**2026 елда Казан шәһәренең җирле әһәмияткә ия**
**гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан**
**муниципаль парковкалар (парковка урыннары) эше турында**

2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы федераль закон, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 30 декабрендәге 7660 номерлы «Казан шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан муниципаль парковкалар булдыру турында»гы карары (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) нигезендә, Россия Федерациясенең Хезмәт кодексына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 24 сентябрендәге 1466 номерлы «2026 елда ял көннәрен күчерү турында»гы карарына, 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы «Татарстан Республикасының бәйрәм һәм истәлекле даталары турында»гы Татарстан Республикасы законына (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) таянып:

1. **Карар бирәм**:

1.1. 2026 елда Казан шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан түләүле муниципаль парковкаларның (парковка урыннарының) түбәндәге бәйрәм көннәрендә һәм бәйрәмнәрне күчерүгә бәйле ял көннәрендә транспорт чараларын куйган өчен түләү алмый торган эш режимын билгеләргә: 1, 2, 5-9 гыйнвар; 23 февраль; 9 март; 1, 11 май; 12 июнь; 4, 6 ноябрь; 31 декабрь; Ураза бәйрәме, Корбан бәйрәме. Ай календаре һәм урнашкан традиция нигезендә Ураза бәйрәме һәм Корбан гаете башлана торган көннәр Татарстан Республикасы Рәисе Указы белән билгеләнә;

1.2. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре

җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән бәйрәм көннәрендә һәм ял көннәрендә Казан шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан муниципаль парковкаларның (парковка урыннарының) түләүсез эш режимын кертү турында юл хәрәкәтендә катнашучыларга массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә **тәкъдим итәм.**

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**